**Республика Татарстан**
**Совет Старомензелябашского сельского поселѐния Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15 март 2019 ел Иске Минзәләбаш авылы № 8

Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Советы карарларының үз көчен
югалтуын тану турында

2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы «Муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын яисә контракт буенча җирле администрация вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру тәртибе хакында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Минзәләбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы " Иске Минзәләбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 10нчы ноябрендәге 17 нче санлы «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Минзәләбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Минзәләбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыруы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарын, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 нчы ноябрендәге 16 нче санлы « Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Минзәләбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан

керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Минзәләбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында Нигезләмәне раслау хакында» карарын үз көчләрен югалткан дип санарга

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат» рәсми порталында урнаштыру (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Советы рәисе А.Р.Мияссарова